ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.07.2021 г. Заинск №456

**«Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьялары нигезендә, дәүләт торак программаларын тормышка ашыру максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында, торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсеннән чыгып, торак урыны мәйданының исәп нормасын гаиләнең бер әгъзасына туры килгән гомуми торак мәйданы 12 кв.м.дан да артмаганда дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданы 18 кв.м. дип билгеләргә.
3. Бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. Үз көчен югалткан дип танырга:
4.1. «Гражданнарга социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча торак бирү өчен исәпкә куйганда торак мәйданы нормалары турында» 2006 елның 04 августындагы 992 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;
4.2. «Гражданнарга социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча торак бирү өчен исәпкә куйганда торак мәйданы нормалары турында» 2006 елның 04 августындагы 992 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 17 февралендәге 302 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.
5. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге әлеге карарны Зәй муниципаль районының

http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

6. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
7 07 75